**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИШЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАРЫ

2017 ел, 20 октябрь № 8

**Авыл җирлеге территориясендә чүп-чар, үләннәр, яфраклар һәм башка калдыкларны яндыру урыннарын билгеләү һәм су алу өчен шартлар тудыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон,«Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 20 сентябрендәге 947 номерлы карары, муниципаль берәмлек Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Даими күзәтү шартларында җилсез һава торышында биналардан якынлыгы 50 метрдан кимрәк булмаган урыннардан башка, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге торак пунктларының гомуми кулланылыштагы җирләрендә учак ягу, шулай ук чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрне ягу тыела,.

2.Авыл торак пунктларында һәм аның янәшәсендәге территорияләрдә урнашкан тышкы су чыганакларынан елының теләсә кайсы вакытында янгын сүндерү өчен су алу шартлары тудырырга.

3.Саклау объектының территориясендә яки аның янында (200 метр радиуста) табигый һәм ясалма су чыганаклары (елгалар, күлләр, бассейннар, градирни һ.б.) булган очракта янгын автомобильләре урнаштыру һәм елның теләсә кайсы вакытында су алу өчен 12х12 метрдан да ким булмаган каты өслекле подъездлар төзекләндерергә.

4.Әлеге карар территориядә янгынга каршы махсус режим кертелгән чорда үз көчен таратмый.

5. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары аша халыкка җиткерергә.

**Ишеево авыл**
**җирлек башлыгы** **Р.Р. Сатдинов**